РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕАТРЯССКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗУР ӘТРӘЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 58-3-05, факс 58-3-05

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**19 .11. 2021** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең Никифоровка торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Зур Әтрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 ст. нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Никифоровка авылы, Ленин урамы, 18А йорт адресы буенча 2021 елның 2 декабрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Никифоровка авыл җирлегенең 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Никифоровка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Никифоровка т. п. зиратны төзекләндерү (хуҗалык материаллары өчен склад төзү: төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);;

- Никифоровка т. п. зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);»

«КАРШЫ» “РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Зур Әтрәч авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемиологик чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Глава**
**Большеатрясского сельского поселения**
**Тетюшского муниципального района**
**Республики Татарстан** **И.Ш. Юнусов**